КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 13 июнь г.Казань № 489

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле, дәүләт хезмәткәрләренә транспорт хезмәте күрсәтү шартларын һәм тәртибен, Дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт максатларында шәхси транспорттан файдаланган өчен компенсация түләү тәртибен раслау турында» 2006 ел, 12 апрель, 167 нче карары белән расланган Дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт максатларында шәхси транспорттан файдаланган өчен компенсация түләү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт вазыйфаларын башкару белән бәйле рәвештә хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын куллануның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле, дәүләт хезмәткәрләренә транспорт хезмәте күрсәтү шартларын һәм тәртибен, Дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт максатларында шәхси транспорттан файдаланган өчен компенсация түләү тәртибен раслау турында» 2006 ел, 12 апрель, 167 нче карары белән расланган Дәүләт хезмәткәрләренә хезмәт максатларында шәхси транспорттан файдаланган өчен компенсация түләү тәртибенең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«3. Компенсация түләү күләме һәм тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән билгеләнә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин